ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**“Җир асты байлыклары турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында”**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 11 мартында
кабул ителде

**1 статья**

“Җир асты байлыклары турында” 1992 елның 25 декабрендәге 1722-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (1999 елның 6 декабрендәге 2486 номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992, № 11 – 12; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2000, № 2 (2); 2001, № 12; 2004, № 7 (I өлеш); 2005, № 4 (I өлеш); 2008, № 3; 2009, № 9 – 10; 2012, № 1, № 7 (I өлеш), № 12 (II өлеш); 2014, № 1 – 2, № 4, № 5, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяда:
а) түбәндәге эчтәлекле яңа унберенче абзац өстәргә:
“Татарстан Республикасы ия булган җир асты байлыклары турындагы геологик мәгълүматтан файдалану тәртибен һәм шартларын билгеләү;”;
б) унберенче абзацны уникенче абзац дип санарга;

2) 7 статьяның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“Татарстан Республикасының геологик мәгълүмат фондын булдыру һәм алып бару;”;

3) 14 статьяның беренче өлешендәге өченче абзацында “тау эшләре калдыкларыннан һәм аларга бәйле эшкәртү производстволарыннан” сүзләрен “файдалы казылмалар чыгару калдыкларыннан һәм аңа бәйле эшкәртү производстволары калдыкларыннан” сүзләренә алмаштырырга;

4) 18 статьяның бишенче абзацында “үзенең тау эшләре калдыкларыннан һәм шуларга бәйле эшкәртү производстволарыннан” сүзләрен “әлеге җир асты

байлыкларыннан файдаланучының эшчәнлеге нәтиҗәсендә барлыкка килгән файдалы казылмалар чыгару калдыкларыннан һәм аңа бәйле эшкәртү производстволары калдыкларыннан” сүзләренә алмаштырырга;

5) 19 статьяның беренче өлешендә:

а) бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“җир асты байлыкларыннан файдалану җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләрендә гамәлгә ашырылса, “Җир асты байлыклары турында” 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Россия Федерациясе Законы нигезендә федераль геологик мәгълүмат фондына һәм аның территориаль фондларына, шулай ук Татарстан Республикасы геологик мәгълүмат фондына җир асты байлыклары хакында геологик мәгълүмат тапшыруны;”;

б) алтынчы абзацта “геологик мәгълүматның федераль һәм территориаль фондларына” сүзләрен “ , әгәр җир асты байлыкларыннан файдалану җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләрендә гамәлгә ашырылса, федераль геологик мәгълүмат фондына һәм аның территориаль фондларына, шулай ук Татарстан Республикасы геологик мәгълүмат фондына” сүзләренә алмаштырырга;

6) 78 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

7) 86 статьяның өченче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Файдалы казылмалар ятмаларын эшкәртү (эчәр сулар белән тәэмин итү яисә сәнәгать объектларын йә авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге объектларны су белән технологик тәэмин итү максатларында кулланыла торган һәм аларны чыгару күләме тәүлегенә 100 куб метрдан артмаган җир асты суларын чыгарудан тыш) расланган техник проектлар һәм җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле эшләрне башкаруның башка проект документациясе, шулай ук, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләт бирелгән федераль башкарма хакимият органнары белән килештереп, җир асты байлыкларының дәүләт фонды белән идарә итүче федераль орган билгели торган, файдалы казылмалар төрләре буенча файдалы казылмалар ятмаларын эшкәртү кагыйдәләре нигезендә гамәлгә ашырыла. Файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган максатларда җир асты байлыкларыннан файдалану расланган техник проектлар һәм җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле эшләрне башкаруның башка проект документациясе нигезендә гамәлгә ашырыла.”.

**2 статья**

“Җир асты байлыклары турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында” 2001 елның 21 ноябрендәге 1193 номерлы Татарстан Республикасы Законының 38 пунктын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2001, № 12) үз көчен югалткан дип танырга.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ
БҮЛЕК
ОБЩИЙ
ОТДЕЛ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан,Кремль
2016 елның 26 марты
№ 19-ТРЗ